Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская д. 66 в, с. Кавзияково
423377
Телефон: 8 85559 4-47-16

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЭУЖИЯК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 66в йорты,Кэужияк авылы,
423377
Телефон:: 8 85559 4-47-16

ОГРН 1061687002992 ИНН/КПП 1636005503/163601001 ОКАТО 92253824000

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
30 январь 2025 ел

КАРАР
№ 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, "җирләү һәм күмү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында Күмү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Башкарма комитет Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 1 февраленнән Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9165,37 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегендә җирләү

хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» карары.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» веб адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф.Ә. Хөснетдинов